# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

06.12.2021 ел                                                                                                    № 24

ТР Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына үзгәрешләр кертү хакында

2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы «2018-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатында

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 300 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район бюджеты һәм авыл җирлеге бюджеты средстволары хисабына 300 мең сум. |

1.2. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

3. Программаны финанслау.

Программаны финанслауның гомуми күләме 300 000 сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финансларны бүлүче – авыл җирлеге башлыгы,

район Башлыгы.

Әлеге финанслау күләмнәре тиешле финанс елына бюджетларны формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкинлек булган саен район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк.

1.3. 2021-2023 елларга Бәтке авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге программасын яңа редакциядә бәян итәрә:

| Объектларның исеме | Егәрлек | Финанслау чыганагы | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Җирле бюджет, мең сумда | | | |
| | | 2021 | 2022 | 2023 | |
| Юл билгеләрен урнаштыру | 1 | 50 | 50 | 50 | |
| «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру | 3 | 50 | 50 | 50 | |
| Барлыгы | | 100 | 100 | 100 | |

2. Әлеге карарны Бәтке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru/) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе В.А. Вәлиева